**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2020 ел, 20 гыйнвар №229

**Апас шәһәр җирлегенең муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карар **итте**:

1. Апас шәһәр җирлеге Советының 2016 елның 12 февралендә кабул ителгән «Апас шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәнең» 18 номерлы карарының «Апас шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы» 1 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 5.7 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) коммерцияле яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түбәндәге очраклардан тыш катнашырга:

- сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан түләүсез катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек хуҗалары ширкәтләренең съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашу;

-коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу (конференция), эшкә алучының Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган вәкиле рөхсәтеннән башка) катнашу ;

- Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советында, Муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау;

- муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган, муниципаль берәмлек исеменнән оешма вәкаләтләрен гамәлгә кую тәртибен йә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр белән) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау;

- федераль законнарда каралган башка очраклар;

б) 5.7 пунктнын түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктчасын белән өстәргә:

«3.1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;»;

в) 18.9 пункт. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18.9. Әлеге Нигезләмәнең 6, 7 статьяларында һәм 17.2 пунктында каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсез булу чорын, отпускта булуын исәпкә алмыйча, коррупциячел хокук бозу турындагы мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларда җинаять эше буенча эш вакыты кертелми.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары Н.Т. Исмәгыйлевага йөкләргә.

**«Апас шәһәр тибындагы поселогы»,**
**муниципаль берәмлек Башлыгы**
**Апас шәһәр җирлеге**
**Советы Рәисе** **Р. Ф. Хисаметдинов**